**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2015 ел, 12 ноябрь | № 851

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аммиак, метанол һәм бөртекләндерелгән карбамид җитештерү заводын төзү буенча республика штабы турындагы нигезләмәне һәм аның составын (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 12 сентябрь, 660 нчы карарын исәпкә алып) раслау турында» 2009 ел, 31 август, 597 нче карары белән расланган Аммиак, метанол һәм бөртекләндерелгән карбамид җитештерү заводын төзү буенча республика штабы (алга таба – штаб) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

штаб составыннан А.Г.Сидоровны, Ф.Х.Туктаровны, Т.Н.Хөрмәтуллинны чыгарырга;

штаб составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Габделганиев Фәрит Солтан улын | Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министрын |
| Чершинцев Валерий Сергеевичны | Менделеевск муниципаль районы башлыгын (килешү буенча). |

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында энергия саклау һәм энергетиканың нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру һәм чараларны яраштыру буенча яраштыру советы оештыру турында» 2010 ел, 26 ноябрь, 940 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 3 май, 358 нче; 2011 ел, 9 август, 644 нче; 2012 ел, 21 июнь, 528 нче; 2012 ел, 7 август, 671 нче; 2014 ел, 12 декабрь, 978 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында энергия саклау һәм энергетиканың нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру һәм чараларны

яраштыру буенча яраштыру советы (алга таба – совет) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

совет составыннан А.Г.Сидоровны чыгарырга;

совет составына Габделганиев Фәрит Солтан улын – Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министрын кертергә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы коллегиясе составын раслау турында» 2010 ел, 14 декабрь, 1062 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 22 февраль, 127 нче, 2013 ел, 31 август, 622 нче, 2013 ел, 25 ноябрь, 920 нче, 2014 ел, 13 февраль, 84 нче, 2015 ел, 20 август, 608 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы коллегиясе (алга таба – коллегия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

коллегия составыннан А.Г.Сидоровны чыгарырга;

коллегия составына Габделганиев Фәрит Солтан улын – Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министрын кертергә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында экологик куркынычсызлык, табигатьтән файдалану һәм санитария-эпидемиология иминлеге буенча ведомствоара комиссия составын раслау турында» 2010 ел, 14 декабрь, 1065 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 21 февраль, 124 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында экологик куркынычсызлык, табигатьтән файдалану һәм санитария-эпидемиология иминлеге буенча ведомствоара комиссия (алга таба – комиссия) составына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

комиссия составыннан Р.А.Абдуллинны, А.Ю.Вафинны, М.Х.Вафинны, Е.Г.Волковны, А.К.Зиннуровны, Б.Х.Зиннуровны, А.Э.Калайданы, И.А.Ларочкинаны, В.В.Морозовны, Р.Х.Мулинны, И.М.Сафиуллинны, А.Г.Сидоровны, Р.М.Фасаховны, П.П.Черновны чыгарырга;

комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Габделганиев Фәрит Солтан улын | Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министрын |
| Гайзатуллин Ринат Рәүф улын | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты рәисе урынбасарын (килешү буенча) |
| Гомәров Рәис Кәлимулла улын | Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министры урынбасарын |
| Осипов Сергей Альбертовичны | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрының беренче урынбасарын |

| | |
|---|---|
| Патяшина Марина Александровнаны | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча территориаль идарәсе җитәкчесен (килешү буенча) |
| Сәйфетдинов Марат Мөхәммәтгали улын | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасарын |
| Чукин Артем Викторовичны | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры урынбасарын |
| Шәмсетдинов Әлфир Сабир улын | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының административ-техник инспекциясе идарәсе башлыгын (килешү буенча); |

Мусин Харис Гайнетдин улы вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министрының беренче урынбасары».

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яшь геологларның республика ачык кыр олимпиадасын үткәрү турында» 2014 ел, 30 май, 365 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 28 май, 384 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Яшь геологларның республика ачык кыр олимпиадасын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

комитет составыннан А.Г.Сидоровны чыгарырга;

комитет составына Габделганиев Фәрит Солтан улын – Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министрын кертергә.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 8 июнь, б-904 нче боерыгына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 19 сентябрь, б-1759 нчы, 2015 ел, 10 июль, б- 1513 нче боерыклары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министры Ф.С.Габделганиевны Түбән Кама сәнәгать узелын үстергәндә экология иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының махсус вәкаләтле вәкиле итеп билгеләргә.»;

әлеге боерык белән расланган Түбән Кама сәнәгать узелын үстергәндә экология иминлеген тәэмин итү буенча ведомствоара даими гамәлдәге эшче төркем (алга таба – эшче төркем) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

эшче төркем составыннан А.Г.Сидоровны чыгарырга;

эшче төркем составына Габделганиев Фәрит Солтан улын – Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министрын, эшче төркем җитәкчесен кертергә.

7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 17 сентябрь, б-1680 нче боерыгы белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 30 ноябрь, б-2135 нче боерыгы белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Чебоксар сусаклагычының су тигезлеге 68 метр нормаль терәү биеклеге билгесенә кадәр күтәрелү аркасында булуы ихтимал тискәре тәэсирне киметү буенча карарлар әзерләү өчен ведомствоара эшче төркем (алга таба – эшче төркем) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

эшче төркем составыннан Х.А.Баһмановны, О.А.Дәминовны, А.Э.Калайданы, А.Г.Сидоровны чыгарырга;

эшче төркем составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Габделганиев Фәрит Солтан улын | Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министрын, эшче төркем рәисен |
| Сафиуллин Дамир Һарун улын | Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасарын |
| Хәбиров Альберт Абдулла улын | Казан районара табигатьне саклау прокурорын (килешү буенча) |

8. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 24 июль, б-1339 нчы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 5 ноябрь, б-2202 нче; 2014 ел, 8 июль, б-1304 нче; 2014 ел, 13 август, б-1599 нчы; 2014 ел, 6 октябрь, б-1980 нче, 2014 ел, 30 декабрь, б-2850 нче, 2015 ел, 2 апрель, б-537 нче боерыклары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында «Ачык Татарстан» проектын тормышка ашыру һәм дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү сыйфатын күтәрү һәм аннан һәркем файдалана алу мөмкинлеген арттыру буенча ведомствоара эшче төркем составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

эшче төркем составыннан А.Г.Сидоровны, С.В.Чепуштановны чыгарырга;

эшче төркем составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Габделганиев Фәрит Солтан улын | Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министрын, эшче төркем рәисен |
| Кузнецов Артем Александровичны | Федераль миграция хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы (килешү буенча). |

9. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 10 октябрь, б-2026 нчы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 23 март, б-466 нчы боерыгы белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2015 елда Татарстан Республикасында Парклар һәм скверлар елын

әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты (алга таба – оештыру комитеты) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

оештыру комитеты составыннан А.Г.Сидоровны чыгарырга;

оештыру комитеты составына Габделганиев Фәрит Солтан улын – Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министрын, эшче төркем җитәкчесен кертергә.

10. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 26 декабрь, б-2806 нчы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 3 июнь, б-1157 нче боерыгы белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Түбән Кама сусаклагычы дәрәҗәсен проект билгесенә кадәр күтәртү буенча чаралар планын әзерләү һәм тормышка ашыру буенча ведомствоара эшче төркем составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

эшче төркем составыннан А.Г.Сидоровны чыгарырга;

эшче төркем составына Габделганиев Фәрит Солтан улын – Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министрын, эшче төркем җитәкчесен кертергә.

11. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 6 март, б-353 нче боерыгы белән расланган «Сәнәгать минераллары: фараз, эзләү, бәяләү мәсьәләләре һәм чыганакларны үзләштерүнең инновацион технологияләре» халыкара фәнни-гамәли конференцияне әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты сотавына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

комитет составыннан А.Г.Сидоровны чыгарырга;

комитет составына Габделганиев Фәрит Солтан улын – Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министрын кертергә.

12. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 11 июнь, б-1258 нче боерыгы белән расланган «Энергия ресурслары нәтиҗәлелеге һәм энергия саклау» XVI Халыкара симпозиумын һәм «Энергетика. Ресурслар саклау – 2016» XVII Халыкара махсуслаштырылган күргәзмәсен оештыру комитеты составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

комитет составыннан А.Г.Сидоровны чыгарырга;

комитет составына Габделганиев Фәрит Солтан улын – Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министрын кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков